**ГЛАВА ПЕЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 с. Пелево,
ул. Советская , д. 9
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПӘРӘҮ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422610 Пәрәү,
Совет урамы, 9 нче йорт,
тел: 8-(84378) -3-46-31
факс: 8-(84378) -3-46-31
e-mail: Pelev.La@tatar.ru

---

**2026елның 09 апреле** **1 номер**

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге башлыгының карарын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны үз көчен югалткан дип тану турында»гы 1009 нчы номерлы Указының 4 нче пунктына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге башлыгы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге башлыгының 2011 елның 5 декабрендәге «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләргә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тәкъдим ителә торган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү, шулай ук Лаеш муниципаль районы Пәрәү авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне саклаулары турында»гы 6 нчы номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (http://laishevo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Пәрәү авыл җирлеге башлыгы:** **Ф.Ф. Тимергалиев**